| | | |
|---|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 24 март № 165

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 24 май, 349 нчы, 2015 ел, 30 март, 198 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслауның гомуми күләме 5 137,73 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча бүлеп:<br>2014 ел – 1 016,48 млн.сум;<br>2015 ел – 3 376,21 млн. сум;<br>2016 ел – 167,76 млн. сум;<br>2017 ел – 144,32 млн. сум;<br>2018 ел – 144,32 млн. сум;<br>2019 ел – 144,32 млн. сум; |

| | |
|---|---|
| | 2020 ел – 144,32 млн. сум.<br>Программаны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акча суммасы чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен тәгаенләнергә тиеш»; |

«Елларга бүлеп программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Елларга бүлеп программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын тулы күләмдә тормышка ашыру 2020 елга түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренең һәм дәүләт учреждениеләренең гомуми санында (банкротлар дип танылган һәм бетерелү процессында булган оешмаларны исәпкә алмыйча) мөлкәтләре составы турындагы мәгълүматлары Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте реестрында актуальләштерелгән дәүләт унитар предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре өлешен 100 процент дәрәҗәсендә сакларга;<br>дәүләт мөлкәтен һәм җир кишәрлекләрен реализацияләүдән һәм файдаланудан алынган керемнәр өлешендә бюджет йөкләмәсен 100 процент үтәүне тәэмин итәргә,<br>кергән үтенечнамәләрнең (законнар нигезендә караудан баш тартылганнардан йә җирләрне икенче категориягә күчерүдән баш тартылганнардан тыш) гомуми санында алар буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектлары әзерләнгән җирләрне бер категориядән икенче категориягә күчерү турындагы үтенечнамәләр өлешен 100 процент дәрәҗәсендә саклауны тәэмин итәргә;<br>Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт шартнамәләренең гомуми санында Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән |

| | |
|---|---|
| | төзелгән шартнамә шартлары 100 процентка үтәлгән хезмәт шартнамәләре өлешен 85 процентка җиткерергә;<br>дәүләт учреждениеләрендәге җир кишәрлекләренең гомуми санында Татарстан Республикасы милкенә теркәлгән, дәүләт учреждениеләрендәге җир кишәрлекләре өлешен 99 процент дәрәҗәсенә җиткерергә;<br>Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт министрлыгы боерыклары нигезендә дәүләт учреждениеләренә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирелгән җир кишәрлекләренең гомуми санында даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукы рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләре өлешен 99,5 процентка җиткерергә;<br>хисап елы башына җир кишәрлеген түләүсез алуга исәпкә баскан күпбалалы гаиләләрнең гомуми санында түләүсез җир кишәрлекләре алган күпбалалы гаиләләр өлешен 75 процентка җиткерергә;<br>дәүләт учреждениеләренең гомуми санында дәүләт мөлкәтеннән файдалануга тикшерү үткәрелгән дәүләт учреждениеләре өлешен 100 процентка җиткерергә;<br>реформалаштырырга планлаштырылган предприятиеләр санында реформалаштырылган (акционерлаштыруның, бетерүнең, үзгәртеп оештыруның төгәлләнгән процедуралары белән) предприятиеләр өлешен 100 процент дәрәҗәсендә саклауны тәэмин итәргә;<br>кертү өчен планлаштырылган инвестицияләр күләменә карата дәүләт катнашындагы оешмаларның устав капиталларына кертелгән инвестицияр күләме өлешен 100 процент дәрәҗәсендә саклауны тәэмин итәргә;»; |

Программаның II һәм III бүлекләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Программаның максатлары, бурычлары, чаралары, көтелә торган соңгы нәтиҗәләр, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары тасвирламасы

Программаның максаты – Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән

идарә итүнең максималь нәтиҗәлелеген, аның керемле булуын һәм саклануын тәэмин итү.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителергә тиеш:

1. Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен һәм җир кишәрлекләрен тулы һәм дөрес исәпкә алуны тәэмин итү

2. Устав капиталларында Татарстан Республикасы өлеше булган акционер җәмгыятьләр һәм дәүләт предприятиеләре белән нәтиҗәле идарә итүне, аларның бөлгенлеккә төшүен профилактикалауны тәэмин итү.

3. Дәүләт мөлкәте һәм җир кишәрлекләре белән нәтиҗәле эш итүне һәм алардан файдалануны тәэмин итү, шул исәптән балансга тотучы оешмалар тарафыннан.

4. Дәүләт мөлкәте составын һәм структурасын оптимальләштерү.

5. Гражданнарның гамәлдәге законнар белән билгеләнгән мөлкәт хокукларын тәэмин итүне оештыру.

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен һәм җир кишәрлекләрен тулы һәм дөрес исәпкә алуны тәэмин итү» бурычы кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрында Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре мөлкәте составы турындагы мәгълүматларны актуальләштерүне тәэмин итү зарур.

«Устав капиталларында Татарстан Республикасы өлеше булган акционер җәмгыятьләр һәм дәүләт предприятиеләре белән нәтиҗәле идарә итүне, аларның бөлгенлеккә төшүен профилактикалауны тәэмин итү» бурычы кысаларында түбәндәге чараларны үтәүне тәэмин итү зарур:

1) устав капиталларында Татарстан Республикасы өлеше 50 процентган 100 процентка кадәр булган акционер җәмгыятьләр һәм дәүләт унитар предприятиеләре эшчәнлегенә икътисадый мониторингны гамәлгә ашыру;

2) дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт шартнамәләренең үтәлешен тикшерүдә тотуны көчәйтү.

«Дәүләт мөлкәте һәм җир кишәрлекләре белән нәтиҗәле эш итүне һәм алардан файдалануны тәэмин итү, шул исәптән балансга тотучы оешмалар тарафыннан» бурычы кысаларында түбәндәге чараларны үтәүне тәэмин итү зарур:

1) дәүләт мөлкәтен һәм җир кишәрлекләрен реализацияләүдән һәм файдаланудан алынган керемнәр өлешендә бюджет йөкләмәсе үтәлешен тәэмин итү;

2) оешмаларның дәүләт мөлкәтеннән файдалануын тикшерү чаралары үткәрү;

3) «Республика казна мөлкәте» дәүләт бюджет учреждениесе эшчәнлеген тәэмин итү;

4) «Матди тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе эшчәнлеген тәэмин итү;

5) җир кишәрлекләренә Татарстан Республикасы милке хокукларын теркәүне тәэмин итү;

6) дәүләт учреждениеләре файдалануындагы җир кишәрлекләреннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын рәсмиләштерүне тәэмин итү;

7) җирләрне бер категориядән икенче категориягә күчерүне тәэмин итү (Татарстан Республикасы милкендәге җирләргә, шулай ук муниципаль һәм шәхси милектәге авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләргә карата);

8) җир кишәрлекләренә һәм бүтән күчемсез милек объектларына, шулай ук җирдә төзү эшләренә дәүләт кадастр бәяләвен үткәрүне оештыру һәм тәэмин итү;

9) гомуми практика табиблары өчен офис урыннары сатып алу.

«Дәүләт мөлкәте составын һәм структурасын оптимальләштерү» бурычы кысаларында түбәндәге чараларны үтәүне тәэмин итү зарур:

1) Хосусыйлаштыруның фаразланган планын (программасын) үтәү;

2) дәүләт катнашындагы оешмаларның устав капиталларына инвестицияләү;

3) Татарстан Республикасы дәүләт милкенә мөлкәт сатып алу.

«Гражданнарның гамәлдәге законнар белән билгеләнгән мөлкәт хокукларын тәэмин итүне оештыру» бурычы кысаларында күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләрен бирү эшен оештыру буенча чараларны үтәүне тәэмин итү.

Әлеге бурычлар һәм чаралар берлектә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән.

Программа чараларын тормышка ашыру 2020 елга түбәндәге төп нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

дәүләт мөлкәтен һәм җир кишәрлекләрен реализацияләүдән һәм файдаланудан алынган керемнәр өлешендә бюджет йөкләмәсен үтәү – 100 процент;

Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренең һәм дәүләт учреждениеләренең гомуми санында (банкротлар дип танылган һәм бетерелү процессында булган оешмаларны исәпкә алмыйча) мөлкәтләре составы турындагы мәгълүматлары актуальләштерелгән Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре өлеше – 100 процент;

дәүләт учреждениеләренең гомуми санында дәүләт мөлкәтеннән файдалануга тикшерү үткәрелгән дәүләт учреждениеләре өлеше – 100 процент;

дәүләт учреждениеләрендәге җир кишәрлекләренең гомуми санында Татарстан Республикасы милкенә теркәлгән, дәүләт учреждениеләрендәге җир кишәрлекләре өлеше – 99 процент;

ТР Мөлкәт министрлыгы боерыклары нигезендә дәүләт учреждениеләре файдалануындагы җир кишәрлекләренең гомуми санында даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукы рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләре өлеше – 99,5 процент;

кергән үтенечнамәләрнең (законнар нигезендә караудан баш тартылганнардан йә җирләрне икенче категориягә күчерүдән баш тартылганнардан тыш) гомуми санында алар буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектлары әзерләнгән җирләрне бер категориядән икенче категориягә күчерү турындагы үтенечнамәләр өлеше  – 100 процент;

дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт шартнамәләренең гомуми санында дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән төзелгән шартнамә шартлары 100 процентка үтәлгән хезмәт шартнамәләре өлеше – 85 процент;

реформалаштырырга планлаштырылган предприятиеләр санында реформалаштырылган (акционерлаштыруның, бетерүнең, үзгәртеп оештыруның төгәлләнгән процедуралары белән) предприятиеләр өлеше – 100 процент;

кертү өчен планлаштырылган инвестицияләр күләменә карата дәүләт катнашындагы оешмаларның устав капиталларына кертелгән инвестицияр күләме

өлеше – 100 процент;

хисап елы башына җир кишәрлеген түләүсез алуга исәпкә баскан күпбалалы гаиләләрнең гомуми санында түләүсез җир кишәрлекләре алган күпбалалы гаиләләр өлеше – 75 процент.

Программада каралган максат, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук чараларны финанслау күләмнәре әлеге Программага кушымтада китерелә.

Программаны тормышка ашыру вакыты – 2014 – 2020 еллар.

### III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслауның гомуми күләме 5 137,73 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 1 016,48 млн.сум;

2015 ел – 3 376,21 млн. сум;

2016 ел – 167,76 млн. сум;

2017 ел – 144,32 млн. сум;

2018 ел – 144,32 млн. сум;

2019 ел – 144,32 млн. сум;

2020 ел – 144,32 млн. сум.

Программаны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акча суммалары чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен тәгаенләнәчәк.»;

Программага теркәлгән кушымтаны бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасына кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 24 март, 165 нче карары редакциясендә)

## «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасының максаты, бурычлары, аның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| Төп чаралар исеме | Үтәүчеләр | Чараларны үтәү вакытлары | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторларның мәгънәләре | | | | | | | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау, млн.сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (төп) | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| **Максат: Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең максималь дәрәҗәдә нәтиҗәле, керемле булуын һәм сакланышын тәэмин итү** | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| **Бурыч: Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен һәм җир кишәрлекләрен тулы һәм дөрес исәпкә алуны тәэмин итү** | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрында Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре мөлкәте составы турындагы мәгълүматларны | Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Мөлкәт | 2014 – 2020 еллар | Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренең һәм дәүләт учреждениеләренең гомуми санында (банкротлар дип танылган һәм бетерелү процессында булган оешмаларны исәпкә | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 13,35 | 9,49 | 7,20 | 7,63 | 7,63 | 7,63 | 7,63 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| актуальләш-терү | министр-лыгы) | | алмыйча) мөлкәтләре составы турындагы мәгълүмат-лары актуальләш-терелгән Татарстан Республикасы дәүләт унитар пред-приятиеләре һәм дәүләт учреждение-ләре өлеше, % | | | | | | | | | | | | | | | |
| **Бурыч: Устав капиталларында Татарстан Республикасы өлеше булган акционер җәмгыятьләр һәм дәүләт предприятиеләре белән нәтиҗәле идарә итүне, аларның бөлгенлеккә төшүен профилактикалауны тәэмин итү** | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Устав капитал-ларында Та-тарстан Рес-публикасы өлеше 50 про-центтан 100 процентка кадәр булган акционер җәмгыятьләр һәм Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятие-ләре эшчән- | ТР Мөлкәт министр-лыгы | 2014 - 2020 еллар | Предприятие-ләрнең гомуми санында финанс-хуҗалык эшчәнлекләре ТР Мөлкәт министрлыгы тарафыннан анализланган Татарстан Республикасы предприятие-ләре өлеше, % | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 14,02 | 9,96 | 7,56 | 8,02 | 8,02 | 8,02 | 8,02 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| легенә икътисадый мониторингны гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт шартнамәләре-нең үтәлешен тикшерүдә тотуны көчәйтү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2020 еллар | Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт шартнамәләре-нең гомуми санында Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән төзелгән шартнамә шартлары 100 процентка үтәлгән хезмәт шартнамәләре өлеше, % | 70 | 73 | 75 | 78 | 80 | 82 | 83 | 85 | 6,01 | 4,27 | 3,24 | 3,44 | 3,44 | 3,44 | 3,44 |
| **Бурыч: Дәүләт мөлкәте һәм җир кишәрлекләре белән нәтиҗәле эш итүне һәм алардан файдалануны тәэмин итү, шул исәптән балансга тотучы оешмалар тарафыннан** | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Дәүләт мөлкә-тен һәм җир кишәрлек-ләрен реализа-цияләүдән һәм файдаланудан алынган ке-ремнәр өле-шендә бюджет йөкләмәсе үтәлешен тәэмин итү | ТР Мөлкәт министр нистр-лыгы | 2014 – 2020 еллар | дәүләт мөлкә-тен һәм җир кишәрлекләрен реализацияләүдән һәм файдаланудан алынган керемнәр өлешендә бюджет йөкләмәсен үтәү, процент | 110,00 | 101,55 | 100,00 | 100,00 | 100,00 | 100,00 | 100,00 | 100,00 | 66,19 | 47,03 | 35,70 | 37,84 | 37,84 | 37,84 | 37,84 |
| Оешмаларның дәүләт мөл-кәтеннән файдалануын тикшерү чаралары үткәрү | ТР Мөлкәт министр нистр-лыгы | 2014 – 2020 еллар | Дәүләт учреж-дениеләренең гомуми санында дәүләт мөлкә-теннән файда-лануга тик-шерү үткәрел-гән дәүләт учреждениеләре өлеше, процент | 50 | 57 | 64 | 67 | 78 | 85 | 92 | 100,0 | 11,35 | 8,06 | 6,12 | 6,49 | 6,49 | 6,49 | 6,49 |
| «Республика казна мөлкәте» дәүләт бюд-жет учрежде-ниесе эшчәнлеген тәэмин итү | ТР Мөлкәт министр нистр-лыгы | 2014 – 2020 еллар | Татарстан Республикасы милкенә теркәлергә планлаштырылган күчемсез милек объектлары | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 5,50 | 5,50 | 5,58 | 6,05 | 6,05 | 6,05 | 6,05 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | санында Татарстан Республикасы милкенә теркәлгән күчемсез милек объектлары өлеше, процент | | | | | | | | | | | | | | | |
| «Матди тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – «МТИ» ДБУ) эшчәнлеген тәэмин итү | ТР Мөлкәт министр нистрлыгы | 2014 – 2020 еллар | «МТИ» ДБУ га беркетелгән транспорт чараларының гомуми санында рейска чыгу тәэмин ителгән транспорт чаралары саны өлеше, процент | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 57,75 | 67,22 | 61,54 | 61,92 | 61,92 | 61,92 | 61,92 |
| Җир кишәрлекләренә Татарстан Республикасы милке хокукларын теркәүне тәэмин итү | ТР Мөлкәт министр нистрлыгы | 2014-2020 | Дәүләт учреждениеләрендәге җир кишәрлекләренең гомуми санында Татарстан Республикасы милкенә теркәлгән, дәүләт учреждениеләрендә- | 90 | 95 | 98 | 99,0 | 99,0 | 99,0 | 99,0 | 99,0 | 4,73 | 3,36 | 2,55 | 2,70 | 2,70 | 2,70 | 2,70 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ге җир кишәрлекләре өлеше, процент | | | | | | | | | | | | | | | |
| Дәүләт учреждениеләре файдалануындагы җир кишәрлекләреннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын рәсмиләштерүне тәэмин итү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2020 еллар | ТР Мөлкәт министрлыгы боерыклары нигезендә дәүләт учреждениеләре файдалануындагы җир кишәрлекләренең гомуми санында даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукы рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләре өлеше, процент | 97,2 | 98,3 | 99,2 | 99,5 | 99,5 | 99,5 | 99,5 | 99,5 | 4,73 | 3,36 | 2,55 | 2,70 | 2,70 | 2,70 | 2,70 |
| Җирләрне бер категориядән икенче категориягә күчерүне тәэмин итү (Татарстан Республикасы милкендәге җирләргә, шулай ук муниципаль һәм | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2020 еллар | кергән үтенечнамәләрнең (законнар нигезендә караудан баш тартылганнардан йә җирләрне икенче категориягә күчерүдән баш тартылган- | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 7,56 | 5,37 | 4,08 | 4,33 | 4,33 | 4,33 | 4,33 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| шәхси милек-тәге авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләргә карата) | | | нардан тыш) гомуми санында алар буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектлары әзерләнгән җирләрне бер категориядән икенче категориягә күчерү турындагы үтенечнамәләр өлеше, про-цент | | | | | | | | | | | | | | | |
| Җир кишәрлекләренә һәм бүтән күчемсез милек объектларына, шулай ук җирдә төзү эшләренә дәүләт кадастр бәяләвен үткәрүне оештыру һәм тәэмин итү | ТР Мөлкәт министр нистр-лыгы | 2014 – 2020 еллар | җир кишәрлекләренә һәм бүтән күчемсез милек объектларына, шулай ук җирдә төзү эшләренә дәүләт кадастр бәяләвен үткәрү буенча чараларның гомуми санында, җир кишәрлекләренә һәм бүтән күчемсез милек | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 10,38 | 31,15 | 28,60 | * | * | * | * |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | объектларына, шулай ук җирдә төзү эшләренә дәүләт кадастр бәяләвен үткәрү буенча башкарылган чаралар өлеше, процент | | | | | | | | | | | | | | | |
| Гомуми практика табиблары өчен офис урыннары сатып алу | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 ел | сатып алырга планлаштырылган урыннарның гомуми санында сатып алынган урыннар өлеше, процент | - | 100,0 | - | - | - | - | - | - | 14,21 | - | - | - | - | - | - |
| **Бурыч: Дәүләт мөлкәте составын һәм структурасын оптимальләштерү** | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хосусыйлаштыруның фаразланган планын (программасын) үтәү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2020 еллар | реформалаштырырга планлаштырылган предприятиеләр санында реформалаштырылган (акционерлаштыруның, бетерүнең, үзгәртеп оештыруның тәгәлләнгән процедуралары белән) | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 1,33 | 0,96 | 0,73 | 0,76 | 0,76 | 0,76 | 0,76 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | предприятие-ләр өлеше, процент | | | | | | | | | | | | | | | |
| Дәүләт катнашындагы оешмаларның устав капиталларына инвестицияләү | ТР Мөлкәт министр нистр-лыгы | 2014 – 2020 еллар | кертү өчен планлаштыры лган инвести-цияләр күләменә карата дәүләт катнашындаг ы оешмаларның устав капиталларын а кертелгән инвестицияр күләме өлеше, процент | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 671,94 | 3 009,85 | * | * | * | * | * |
| Татарстан Республикасы дәүләт милкенә мөлкәт сатып алу | ТР Мөлкәт министр нистр-лыгы | 2014 – 2020 еллар | Татарстан Республикасы дәүләт милкенә сатып алырга планлаштыры лган мөлкәт күләменә карата Татарстан Республикасы дәүләт милкенә сатып алынган мөлкәт күләме өлеше, процент | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 123,16 | 167,59 | * | * | * | * | * |
| **Бурыч: Гражданнарның гамәлдәге законнар белән билгеләнгән мөлкәт хокукларын тәэмин итүне оештыру** | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләрен бирү эшен оештыру | ТР Мөлкәт министрнистр-лыгы | 2014 – 2020 еллар | хисап елы башына җир кишәрлеген түләүсез алуга исәпкә баскан күпбалалы гаиләләрнең гомуми санында түләүсез җир кишәрлекләре алган күпбалалы гаиләләр өлеше, процент | 81,0 | 93,0 | 75,0 | 75,0 | 75,0 | 75,0 | 75,0 | 75,0 | 4,27 | 3,04 | 2,31 | 2,44 | 2,44 | 2,44 | 2,44 |
| **Программа буенча барлыгы:** | | | | | | | | | | | | **1 016,48** | **3 376,21** | **167,76** | **144,32** | **144,32** | **144,32** | **144,32** |

*ихтыяҗ Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә